**СОВЕТ ГАБИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422606 с. Габишево,
пр. Молодежный, д.1
тел: 4-46-57

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГАБИШЕВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422606 Габишев авылы,
Яшьләр урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-46-57

**2025 елның 25 декабре** **26 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 12 апрелендәге 5.3 номерлы Габишев авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 декабрендәге 994 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 12 апрелендәге 5.3 номерлы Габишев авыл җирлеге Советы карарына (10.05.2018 №9, 18.10.2018 №22, 29.10.2020 №11, 14.10.2022 №6, 18.11.2022 №12, 20.01.2023 №34, 24.06.2024 №130, 08.11.2024 №154, 30.04.2025 №189номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге Советы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта «15 389» саннарын «16 928» саннары белән алыштырырга;

Күрсәтелгән карарның 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (кушымта)бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә туны муниципаль районның Габишев авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Ф. Миндубаев**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләрендә һәм шәһәр торак пунктларында | | | |
| | Тугызынчы төркем <*> | Унынчы төркем <*> | Унберенче төркем <*> | Уникенче төркем <*> |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 31 496 | 27 601 | 25 401 | 23 201 |

<*> Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлек кергән хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләмен билгеләү максатыннан тиешле муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына карап түбәндәге хезмәт хакы төркемнәре буенча бүленә:

1) шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә барлыкка килгән авыл һәм шәһәр торак пунктлары:

тугызынчы төркем 10 меңнән артык кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;

унынчы төркем - халык саны 5 меңнән 10 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

унберенче төркем - 1,5 меңнән 5 меңгә кадәр кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;

уникенче - төркем халык саны 1,5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр.